# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

"Җир реформасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1. "Җир реформасы турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992 ел, N2, 1993 ел, N5) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

<u>1 статья.</u> 1 статьяның 1 өлешендәге "гражданнарга, предприятиеләргә, оешмаларга, учреждениеләргә, берләшмәләргә, кооперативларга һәм ширкәтләргә, аларның җиргә булган хокукларын җир бирү" дигән сүзләрне "гражданнарга, коммерция оешмаларына һәм коммерциягә карамаган оешмаларга аларның җиргә булган хокукларын... җир кишәрлекләре бирү" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

<u>2 статья.</u> 2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасында җир, җир асты байлыклары - бөтен халык байлыгы була. Җир кишәрлекләре хосусый милек, дәүләт (шул исәптән республика милке һәм коммуналь) милке, җирле үзидарә милке һәм иҗтимагый берләшмәләр милке булырга мөмкин".

<u>3 статья.</u> 4 статьяның 1 өлешендәге "биләүгә яисә" дигән сүзләрдән соң "чикләнмәгән вакытка яки билгеле бер чорга файдалануга, шул исәптән арендага" дигән сүзләр өстәргә.

4 статьяның 2 өлешендәге "Җирне кире кайтарып бирү" дигән сүзләрне "Җир кишәрлекләрен кире кайтарып бирү" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

4 статья. 5 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җир кишәрлекләре коммерция оешмаларының һәм коммерциягә карамаган оешмаларның гомуми (уртак һәм өлешле) милкенә тапшырылырга мөмкин".

5 статья. 7 статьяның 1 өлешендә "җир" сүзен "җир кишәрлекләре" дигән, "халык депутатлары Советлары" дигән сүзләрне "халык депутатларының җирле Советлары" дигән сүзләргә алмаштырырга.

7 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацында "дүртенче өлешендә" дигән сүзләрне " өченче өлешендәге икенче абзацында" дигән сүзләргә алмаштырырга.

7 статьяның 2 өлешендәге өченче абзацында "җиргә күмәк (уртак, өлешле) милек" дигән сүзләрне " җир кишәрлегенә гомуми (уртак, өлешле) милек" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

7 статьяның 3 өлешендәге икенче абзацында "җиргә күмәк (уртак, өлешле) милек" дигән сүзләрне "җир кишәрлегенә гомуми (уртак, өлешле) милек" дигән сүзләргә алмаштырырга.

6 статья. 8 статьяда "җирнең варисы булу" дигән сүзләрне "җир кишәрлегенең варисы булу" дигән сүзләргә алмаштырырга.

7 статья. 9 статьяда "Җир милекчеләре" дигән сүзләрне "Җир кишәрлекләре милекчеләре" дигән сүзләргә алмаштырырга.

8 статья. 10 статьяның 1 өлешендә "җир милекчеләре" сүзләрен "җир кишәрлекләре милекчеләре" дип алмаштырырга.

10 статьяның 2 өлешендә "махсус исәп" сүзләре урынына "тиешле ... махсус бюджет исәпләре" дигән сүзләр язарга "халык депутатлары җирле Советларының" дигән сүзләрдән соң "җирле үзидарә органнарының" дигән сүзләр өстәргә.

10 статьяның 3 өлешендә "Җиргә" сүзен "Җир кишәрлекләренә" дип алмаштырырга.

9 статья. 11 статьяның 1 өлешендә "Җир милекчеләре" дигән сүзләрне "Җир кишәрлекләре милекчеләре" дигән сүзләргә алмаштырырга һәм "акчалары" дигән сүзе алдыннан "җирле бюджет" дип язарга, калганнарын төшереп калдырырга.

11 статьяның 2 өлешендә "өчен" сүзеннән соң килүче "җир биләүчеләр" дигән сүзләр урынына "җир кишәрлекләре милекчеләре" дип язарга.

<u>10 статья.</u> 12 статьяның 1 өлешендә "халык депутатлары Советларының" дигән сүзләрне "халык депутатларының җирле Советлары" дигән сүзләргә алмаштырырга.

12 статьяның 2 өлешендә "җир" сүзен "җир кишәрлеге" дигән сүзләргә алмаштырырга.

12 статьяның 3 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә: "Гражданнар милкенә бирелгән җир кишәрлекләре законда билгеләнгән тәртиптә тартып алынырга мөмкин."

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 19 декабре
№ 920